Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге
Күн торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

6 декабрь, 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Күн торак пунктында 2019 елның 6 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 592 (биш йөз туксан ике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 313 (өч йөз унөч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 313 (өч йөз унөч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2020 елда Питрәч муниципаль Күн авыл җирлегенең Күн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, көндезге уку формасы студентларыннан тыш үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов